КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 май г.Казань № 406

Дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында махсус эш режимы турында

Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу куркынычына бәйле рәвештә һәм «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе территориясенә яңа коронавирус йогышлы авыруын кертүне һәм таратуны кисәтү буенча оператив штаб карарларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (алга таба – учреждениеләр) үз эшчәнлеген 1 – 4 нче кушымталар нигезендә махсус эш режимында гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

түбәндәгеләрне расларга:

санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәрге чорга, смена эше дәвамлылыгын кимендә 14 календарь көн билгеләп, учреждениеләр хезмәткәрләре алмашыну графикларын;

учреждениеләрнең сменалы эш режимы билгеләнәчәк хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеген;

яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәрендәге затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләр хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм

өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне билгеләү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Бу карарның гамәле 2020 елның 21 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 май, 406 нчы
карарына 1 нче кушымта

2020 елның 21 апреленнән үз эшчәнлеген
махсус эш режимында гамәлгә ашыручы дәүләт стационар
социаль хезмәт күрсәтү оешмалары исемлеге

1. «Яр Чаллы картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ[1];
2. «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Асылташ» социаль приюты» ДКУ[2];
3. «Түбән Кама муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Балкыш» социаль приюты» ДКУ;
4. «Питрәч муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Шатлык» социаль приюты» ДКУ;
5. «Казан психоневрология интернаты» ДАСХКУ;
6. «Тернәкләндерүнең заманча медик-социаль технологияләре кулланыла торган Кама Аланы психоневрология интернаты» ДАСХКУ;
7. «Акылга зәгыйфь балалар өчен Дербышки балалар интернат йорты» ДКУ;
8. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Казан шәһәре» шәһәр округындагы Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Милосердие» социаль адаптация үзәге» ДАСХКУ;
9. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яр Чаллы шәһәре» шәһәр округындагы Билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Перекресток» социаль адаптация үзәге» ДАСХКУ.

---

[1]ДАСХКУ – дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;
[2]ГКУ – дәүләт казна учреждениесе.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 май, 406 нчы
карарына 2 нче кушымта

2020 елның 22 апреленнән үз эшчәнлеген
махсус эш режимында гамәлгә ашыручы дәүләт стационар
социаль хезмәт күрсәтү оешмалары исемлеге

«Чүпрәле муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Теплый дом» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесе.

______________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 май, 406 нчы
карарына 3 нче кушымта

2020 елның 24 апреленнән үз эшчәнлеген
махсус эш режимында гамәлгә ашыручы дәүләт стационар
социаль хезмәт күрсәтү оешмалары исемлеге

1. «Азнакай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ[1];
2. «Арча картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
3. «Лесхоз картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
4. «Мамадыш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
5. «Тәтеш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
6. «Зеленодольск психоневрология интернаты» ДАСХКУ;
7. «Яңа Чүриле психоневрология интернаты» ДАСХКУ;
8. «Акыл үсеше артта калган балалар өчен Югары Отар балалар интернат йорты» ДКУ[2];
9. «Бөгелмә муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Ялкын» социаль приюты» ДКУ;
10. «Зеленодольск муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Гнездышко» социаль приюты» ДКУ;
11. «Бөгелмә муниципаль районында билгеле яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен «Маяк» социаль адаптация үзәге» ДАСХКУ.

[1]ДАСХКУ – дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;
[2]ГКУ – дәүләт казна учреждениесе.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 май, 406 нчы
карарына 4 нче кушымта

2020 елның 24 апреленнән үз эшчәнлеген
махсус эш режимында гамәлгә ашыручы дәүләт стационар
социаль хезмәт күрсәтү оешмалары исемлеге

1. «Алабуга картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ[1];
2. «Алабуга психоневрология интернаты» ДАСХКУ;
3. «Актаныш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
4. «Алексеевск картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
5. «Әлки картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
6. «Баулы картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
7. «Буа картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
8. «Югары Ослан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
9. «Җәлил картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
10. «Кайбыч картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДБУ[2];
11. «Корноухово картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
12. «Лениногорск картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
13. «Минзәлә картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
14. «Мөслим картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
15. «Чистай психоневрология интернаты» ДАСХКУ;
16. «Аксубай муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен «Мечта» социаль приюты» ДКУ[3];
17. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Яңа Чишмә картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
18. «Нурлат картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
19. «Спас картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
20. «Тукай картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
21. «Федоровка картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
22. «Чирмешән картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ;
23. «Чистай «Юлдаш» картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ.

---

[1]ДАСХКУ – дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;
[2]ДБУ – дәүләт бюджет учреждениесе;
[3]ДКУ – дәүләт казна учреждениесе.